СОВЕТ КУРАЛОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ КУРАЛОВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

РЕШЕНИЕ 17.12.2015 | КАРАР 5-33

с. Куралово

Җирле референдум үткәрү инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 пункты, Куралово авыл җирлеге Уставының 11 статьясы нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районы
Куралово авыл җирлеге Советы
КАРАР ИТТЕ:

1. Куралово авыл җирлеге территориясендә җирле референдум үткәрүнең уртак инициативасын тәкъдим итү:

«Сез 2016 елда җирле референдумда катнашу хокукына ия авыл җирлегенең һәр кешесеннән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

- Рус Борнашы авылында һәм Куралово авылында урнашкан 2 км озынлыктагы зиратларга килү юллары төзү .

"ӘЙЕ " " ЮК.

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга

3. Әлеге карар имзаланган көннән үз көченә керә.

Совет Рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Куралово авыл җирлеге башлыгы: Л. И. Коткова